**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Наратлы авыл җирлеге составына керүче Петровка поселогындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

2019 елның 09 ноябре № 1
14.00 сәг.
Петровка п., Петровская ур.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, нигезендә 2019 елның 09 ноябрендә үзара салым кертүгә Бөгелмә муниципаль районының Петровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә, инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары төркеменнән тыш, һәм катнашучылардан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә багышланган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. Әлеге мәсьәлә буенча “Бөгелмә районының Петровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2019 елда үзара салым кертүгә 300 (өч йөз) сум күләмендә салым алу һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?” дигән түбәндәге сорау язылган иде:

- Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларга һәм тыл хезмәтчәннәре истәлегенә куелган һәйкәлне ремонтлау өчен

ӘЙЕ ЮК

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә ярашлы рәвештә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 37 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 27 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 27 катнашучы тавыш бирде;

"Юк" позициясе өчен гражданнар җыенының 0 катнашучысы тавыш бирде, җыенның 0 катнашучысы тыелып калды.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Наратлы авыл җирлеге составына керүче Петровка поселогында гражданнар җыенын һәм аның нәтиҗәләрен- дөрес дип танырга.

2. Бөгелмә муниципаль районының Петровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларга һәм тыл хезмәтчәннәренә куелган һәйкәлне ремонтлау өчен салым алу белән килешәсезме? дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Петровка торак пунктының махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында «Интернет» челтәрендә (http://bugulma.tatar.ru, «Авыл җирлекләре» бүлегенең «Наратлин авыл җирлеге» бүлекчәсендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә)

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Наратлы авыл җирлеге башлыгы** **С.А. Дмитриев**